**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2016 елның 15 апреле № 45

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының « Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**

Бишнә авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге 45 номерлы карарына Кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәрләр коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә бурычлы.

Хәбәр язма рәвештә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә алырлык шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәрнамә рәвешендә рәсмиләштерелә (алга таба – хәбәрнамә).

3. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә әлеге Нигезләмәнең кушымтасы нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамәне җибәрә.

4 Яллаучы вәкиленә кергән хәбәрнамәләр карау өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында (алга таба – Комиссия, комиссияләр) барлыкка килә торган мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү буенча тиешле комиссияләргә тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләр, аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар җибәргән затлардан алырга һәм билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрергә хокуклы.

5. Гаризаларны алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар комиссия утырышына тапшырыла, ул хәбәрнамәләр комиссиягә кергән көннән җиде эш көне эчендә үткәрелә.

Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән запрослар җибәргән очракта, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар, гаризалар алынган көннән алып, 45 көн эчендә комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артык түгел.

6. Комиссия белдерүләрне карый һәм Бишнә авыл җирлеге Советы карары белән расланган комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны яллаучы вәкиленә җибәрә.

7. Яллаучы вәкиле тарафыннан комиссия тарафыннан карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

б) хәбәрнамә җибәргән затның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә алуын танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар үтәлмәде дип танырга.

8. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә, яллаучы вәкиле мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрә яисә чаралар күрүне тәэмин итә йә хәбәрнамә җибәргән Затка мондый чаралар күрергә тәкъдим итә.

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, яллаучы вәкиле Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын куллана.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүен хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә Кушымта

___________________________
(танышу турында билге)

___________________________
(представителю нанимателя)

___________________________
(Ф.И.О., вазифа)

**вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәрнамә**

Минем **вазыйфаи бурычларны үтәгәндә** мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә алуын кызыксынуым турында хәбәр итәм(кирәкне ассызыклау).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган шартлар: ___________
___________________________________________________________

Вазыйфаи бурычлар, аларны үтәүдә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксыну: ___________________________________
___________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ___________________________________________
___________________________________________________________

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы Аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм (теләмим) (ассызыкларга кирәк).

«____»________________ 201_ г. ____________________ ____________________
(хәбәрнамәне җибәргән затның имзасы) (имзаны киңәйтү)